ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

от “26” ноябрь 2025 ел № 6

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Ашытбаш авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

"Ачык хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында" 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, "Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Арча муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге Уставының 25 статьясы, Арча муниципаль районының Ташкичү авыл җирлеге муниципаль берәмлеге башлыгы карар чыгарды:

«Сез 2026 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Ашытбаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 500 сум, 1 нче һәм 2 нче төркем инвалидларга, 75 яшьтән узган гражданнарга, көндезге формада белем алучы студентларга 250 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарны, ир белән хатынны, балигъ булган балаларны) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (юл-урам челтәрендә сафтан чыккан яктырту приборларын алыштыру өчен яктырткычлар сатып алу, ут челтәрләрен ремонтлау);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирле әһәмияттәге юл-

урам челтәренең юл полотносы нигезләү һәм каплау: Пушкин урамы һәм зират капкасына кадәрге юл);

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су җыю манараларын, коеларын һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, китерү һәм халыкны су белән тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (челтәрләренең аварияле участокларын өлешчә ремонтлау);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (агачларны кисү);

- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), табигый яисә ясалма сулык ярындагы янгын сүндерү автомобильләре өчен махсус корылмаларны төзү, ремонтлау (помпа сатып алу)

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

Халык җыены беркетмәсе (йомгаклау беркетмәсе) нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 421 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 236 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 231 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 5 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Ашытбаш авылында халык җыенын булып узган дип таныргa, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. «Сез 2026 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге Ашытбаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 500 сум, 1 нче һәм 2 нче төркем инвалидларга, 75 яшьтән узган гражданнарга, көндезге формада белем алучы студентларга 250 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарны, ир белән хатынны, балигъ булган балаларны) түләүдән азат

итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар урнашкан мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәсен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны ремонтлау (юл-урам челтәрендә сафтан чыккан яктырту приборларын алыштыру өчен яктырткычлар сатып алу, ут челтәрләрен ремонтлау);

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең юл полотносы нигезләү һәм каплау: Пушкин урамы һәм зират капкасына кадәрге юл);

- су белән тәэмин итү һәм су чыгару системаларын, су җыю манараларын, коеларын һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алу, аны чистарту, китерү һәм халыкны су белән тәэмин итә торган башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (челтәрләренең аварияле участокларын өлешчә ремонтлау);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (агачларны кисү);

- янгынга каршы резервуарларны (янгын сулыкларын), табигый яисә ясалма сулык ярындагы янгын сүндерү автомобильләре өчен махсус корылмаларны төзү, ремонтлау (помпа сатып алу)

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

- мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына РТ, Арча районы, Ашытбаш авылы, Г.Тукай урамы, 19 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Ташкичү  авыл җирлеге башлыгы Р.Х.Хабибуллин